| | | |
|---|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>НУРЛАТСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ<br>РАЙОН<br>ГЛАВА ЧУЛПАНОВСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>ЧУЛПАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ** |
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | Чулпан ав. | **КАРАР** |
| « 29 » март 2024 ел | | № 1 |

Нурлат муниципаль районы Чулпан авыл җирлеге Чулпан авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Чулпан авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Чулпан авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ**:**

1. 2024 елның 10 апрелендә 10 сәгать 00 минутка Чулпан авылы, М. Җәлил урамы, 70нче йорт адресы буенча урнашкан КФҮ бинасына Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Чулпан авыл җирлеге Чулпан авылында Үзәк урамы, Кыр, Күл, Подстанция, Көнчыгыш, Болын, Лермонтов урамнарында, Лермонтов тыкрыгында, Гоголь урамында яшәүче гражданнардан үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының беренче этабын уздыруны билгеләргә
2. 2024 елның 10 апрелендә 12 сәгать 00 минутка Чулпан авылы, М. Җәлил урамы, 70 нче йорт адресы буенча урнашкан КФҮ бинасына Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Чулпан авыл җирлеге Чулпан авылында Шоссе урамы, Тукай, М.Җәлил, Елга арьягы, урамнарында яшәүче гражданнардан үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының икенче этабын уздыруны билгеләргә.
3. 2024 елның 10 апредендә 14 сәгать 00 минутка Чулпан авылы, М. Җәлил урамы, 70 нче йорт адресы буенча урнашкан КФҮ бинасына Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Чулпан авыл җирлеге Чулпан авылында Мәктәп урамы, Төньяк, Бакча, Пушкин, Овражная, Хастаханә территориясе урамнарында яшәүче гражданнардан үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының өченче этабын уздыруны билгеләргә.
4. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Чулпан авыл җирлеге Чулпан авылында яшәүчеләрнең исемлеген гражданнар җыенын үткәрү өчен территориаль билге буенча бүләргә.
5. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Чулпан авыл җирлегендә халык җыены этапларын уздыру һәм оештыруны Чулпан авыл җирлеге башлыгы һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Чулпан авыл җирлеге башкарма комитеты тәэмин итә.
6. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез элек расланган гражданнар җыенында кертелгән сорауларга үзгәрешләр кертүгә ризамы;

- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Чулпан авыл җирлегенең Чулпан авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында 18.10.2023 № 1 карары:

- Нурлат муниципаль районы Чулпан авыл җирлегенең Чулпан авылы торак пунктында гражданнар Җыенының 18.10.2023 2 карары аны түбәндәге редакциядә расларга:

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Чулпан авыл җирлеге Чулпан авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешедән алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп, 2024 елда 1500 сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы:

- урам яктырту җайланмасы;

торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту;

«РИЗА» «КАРШЫ»

7. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (игълан итәргә) http://pravo.tatarstan.ru һәм Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Чулпан авыл җирлеге Чулпан авылының мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча урнаштырырга.

8. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Чулпан авыл җирлеге башлыгы Ф.Ф. Зыятдинов